ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 п.г.т.Алексеевское № 465

**2023 елга Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгати-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Алексеевск муниципаль районы муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2023 елга расларга:

«Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны (Кушымта);

балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 0,65 күләмендә норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициенты.

2. «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы (Леденцов О. Н.) әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.10.2022 № 465 карарына
кушымта

## НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

**Алексеевск муниципаль районында балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (сумнарда бер укчыга) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртә профес-сиональ ориентация |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Рәсем сәнгате | шәһәр җирлеге | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореографик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомум эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 35 168 | | |
| | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгать | шәһәр җирлеге | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театраль сәнгать | шәһәр җирлеге | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |
| | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |